Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет төп гомуми белем учреждениесе
«Шубан төп гомуми белем бирү мәктәбе»

# Сыйныф җитәкчеләренең методик берләшмә утырышында күрсәтелгән “Әй калфагым, калфагым “ дип аталган мастер-класс эшкәртмәсе

**Беренче категорияле башлангыч сыйныф укытучысы**
**Шарипова Лилия Ураловна**

**апрель ,2022 ел**

**Мастер-класс**

**Тема:** ***Әй калфагым, калфагым***
***Калфаклар кияр чагым.***

**Максат:** -милли традицияләребез нигезендә ятучы кыйммәтле, милли, әхлаклы сыйфатларны саклау;
-татар хатын-кызларының милли баш киеме – калфак турында мәгълүмат бирү;
- милли мәдәниятыбызга ихтирам һәм мәхәббәт хисе тәрбияләү.

**Мастер-класс барышы**

**1. Исәнләшү. Оештыру.**

-Исәнмесез, хөрмәтле коллегалар! Матур сүзләр әйтеп , елмаеп хәлләрне белик.
*Хәерле көннәр сезгә,*
*Осталык һәм тел ачкычы*
*Телимен һәммәгезгә.*

**2. Мотивлаштыру**.

-Әйдәгез, кәефебезне тагын да яхшыртыр өчен, бер-беребезгә матур сүзләр әйтеп, кулларны кулга куйыйк. Шулай чылбыр төзик. Чылбырыбыз нык булсын. Рәхмәт! Менә бит нинди яхшы, матур, ныклы чылбыр килеп чыкты. Кулларыбызның җылысы аша йөрәк җылыбызны белдек. Бер – беребезгә яхшы мөнәсәбәттә икәнебезне белдек һәм менә шул хис безне мастер – класс вакытында да ташламас, бер – беребезгә ярдәм итәрбез дип ышанып калам.

**<u>3. Калфак турында белешмә бирү.</u>**

-Татар кызын иң элек ишетәсең , аннан гына күрәсең” – дигән әйтем бар. Чыннан да элек татар кызларының бизәнү әйберләре шулкадәр күп булган, атлаган саен чылтырап торганнар алар. Барсыннан да ныграк чулпылар чыңлаган. Элек хәтта чулпы авырлыгыннан чәчләр тизрәк үсә дип тә уйлаганнар. Чулпы, беләзек, алка һәм башка шундый бизәнү әйберләренең авырлыгы 80 кг. җитә торган булган. Чәч юлы турысына киеп куелган калфак кызларның йөз сылулыгын ассызыклап торучы баш киеме- калфак турында искә төшереп китик әле.
КАЛФАК хатын – кызларның бик яраткан баш киеме булган. Кичләр утырып кызлар серләшә – серләшә матур бизәкләр төшергәннәр. Шушы матур калфакларны алар бәйрәмнәргә, кунакларга барганда киеп барганнар. Билгеле затлы костюмнаргада бик килешкән бит ул. Шул ук вакытта йола ягыннан карасак йола белән дә бәйле бит ул : татар кызлары беркайчан да чәчләрен күрсәтеп йөрмәгәннәр, һәрвакыт шушы калфакта булганнар.

**4. Калфак эшләү.**

- Бүген без үзебезне милли остаханәдә дип хис итик. Үз кулларыбыз белән калфак эшләп карыйк. Инде хәзер ике төркемгә бүленеп урыннарга утырсак иде. (Үрнәк нигезендә әзер өлешләрне ябыштырып җыю)

**5. Эшләрне бәяләү.**

-Хәзер телевидение, радио, интернет челтәре туктаусыз реклама әйләндереп тора. Төркемнәр, калфакларыгызны бер-берегезгә реклама ярдәмендә тәкъдим итегез әле.

Калфагымны кидем мин
Ераклардан килдем мин
Төскә матурлыгым белән

Шаккатырыйм әле мин.

- Бик матур булган рәхмәт сезгә! Кул җылысы, бигрәк тә күңел җылысын биреп башкарылган эш һәрчак уңышлы була.

-Мондый калфакны технология дәресләрендә дә, дәрестән тыш эшчәнлек кысаларында “Оста куллар” түгәрәгендә дә эшләргә мөмкин.
6. **Рефлексия.** Йомгаклап шуны әйтәсем килә. Милли киемнәребезне истә тотып аны киләчәк буыннарга җиткерү безнең бурычыбыз. Милләтебезгә булган хөрмәтебездә. Яхшыны – яманнан аера белгән, матурлыкны яраткан, гореф – гадәтләрен онытмаган балалар киләчәктә үз юлларын табарлар дип ышанып калам.
Хөрмәтле коллегалар, мастер- класста актив катнашуыгыз өчен өчен бик зур рәхмәт.